Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №Х-3**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга милеккә җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсендәге 6 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 12 июлендәге XVIII-13 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә бирү (тапшыру) Тәртибенең 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре бирү белән кызыксынучы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә даими көн итүче гражданнарга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Анатыш, Бәтке, Котлы Бүкәш, Троицкий Урай һәм Олы Елга авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләре бирергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 маддәсе нигезендә җир кишәрлекләрен түләүсез алу хокукына ия гражданнарга җир кишәрлекләрен милеккә бирү турында” 2012 елның 5 сентябрендәге XIX-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М. ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова